| | |
|---|---|
| КОМИТЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>ПО СОЦИАЛЬНО-<br>ЭКОНОМИЧЕСКОМУ<br>МОНИТОРИНГУ | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ<br>СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДЫЙ<br>МОНИТОРИНГ<br>КОМИТЕТЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**27.12.2018** г. Казань **N 61-ос**

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый комитетында биләүләре коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының 13.12.2017 № 50-ос боергы белән расланган исемлегенә үзгәреш кертү хакында

1. Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый комитетында (алга таба – Комитет) биләүләре коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының исемлегенә (алга таба – Исемлек), яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (кушымта итеп бирелә).

2. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторы исемлеккә кертелгән Комитет дәүләт граждан хезмәткәрләрен әлеге боерык белән таныштырырга һәм боерык күчермәсен, Татарстан Рсепубликасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәве узганнан соң өч көн эчендә Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенә, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына җибәрергә тиеш.

3. Юридик сектор әлеге боерыкның Татарстан Рсепубликасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәве узуын тәэмин итәргә тиеш.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Комитет рәисе урынбасары О.Ю. Семеновга йөкләргә.

Рәис В.П.Кандилов

Татарстан Республикасының
Социаль-Икътисадый мониторинг комитетының
2017 елның 13 декабрендәге № 50-ос
(Татарстан Республикасының
Социаль-Икътисадый мониторинг комитетының
2018 елның «17» декабрендәге № 61-ос боерыгы
редакциясендә) боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый комитетында биләүләре коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

1. Төп вазыйфалар төркеменең «җитәкчеләр» категориясе Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфлары:

рәис урынбасары.

2. Әйдәүче вазыйфалар төркеменең «җитәкчеләр» категориясе Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфлары:

муниципаль берәмлекләрнең һәм предприятиеләрнең социаль-икътисадый хәлен мониторинглау бүлеге башлыгы;

мәгълүмат-аналитика бүлеге башлыгы;

мәгълүмат ресурслары һәм технологияләр бүлеге башлыгы;

финанс бүлеге башлыгы ;

муниципаль берәмлекләрнең һәм предприятиеләрнең социаль-икътисадый хәлен мониторинглау бүлеге башлыгы урынбасары;

мәгълүмат-аналитика бүлеге башлыгы урынбасары;

юридик сектор мөдире.

3. Әйдәүче вазыйфалар төркеменең «белгечләр» категориясе Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфлары:

дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторының әйдәүче киңәшчесе;

муниципаль берәмлекләрнең һәм предприятиеләрнең социаль-икътисадый хәлен мониторинглау бүлегенең әйдәүче киңәшчесе;

мәгълүмат ресурслары һәм технологияләр бүлегенең әйдәүче киңәшчесе.

4. Әйдәүче вазыйфалар төркеменең «тәэмин итүче белгечләр» категориясе Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфлары:

финанс бүлегенең әйдәүче белгече;

мәгълүмат ресурслары һәм технологияләр бүлегенең әйдәүче белгече.

5. Өлкән вазыйфалар төркеменең «тәэмин итүче белгечләр» категориясе Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфлары:

финанс бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече (контракт хезмәт әгъзасы);

муниципаль берәмлекләрнең һәм предприятиеләрнең социаль-икътисадый хәлен мониторинглау бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече;

дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторының 1 разрядлы өлкән белгече;

муниципаль берәмлекләрнең һәм предприятиеләрнең социаль-икътисадый хәлен мониторинглау бүлегенең 1 разрядлы  белгече.